| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА ЯКУШКИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>НУРЛАТСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЯКУШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

Якушкино ав.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» март 2024 ел № 4

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Салдакай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районының Якушкино авыл җирлеге башлыгы

КАРАР БИРӘ**:**

1. 2024 елның 11 апрелендә Салдакай авылы, Үзәк урамы, 18 йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында 11 сәгать 00 минутка Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Якушкино авылы гражданнарының элек расланганнарга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү мәсьәләсе буенча җыенын билгеләргщ:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлегенең Салдакай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 24.11.2023 ел no 5 карары;
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлегенең Салдакай авылында гражданнар Җыенының 24.11.2023 ел, № 6 карары.

2. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

3.1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлегенең Салдакай авылында 24.11.2023 ел, № 5 гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карарның 1 пунктына үзгәрешләр кертергә ризамы, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлегенең Салдакай авылында гражданнар җыены узган дип танылсын, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга

"Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Салдакай авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, 2024 елда 1000(бер мең) сум күләмендә Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары һәм уку йортларында көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;
2) урам яктырту җайланмасы (лампаларны сатып алу һәм алыштыру);
3) торак пункт территориясен төзекләндерү ( паркны саклау) кабул ителгән.

3.2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлегенең Салдакай авылы торак пунктында гражданнар Җыенының 24.11.2023 ел, № 6 карарына аны түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә ризамы:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Салдакай авылы территориясендә теркәлгән 1 гр инвалидлардан тыш, Бөек Ватан сугышы ветераннары , Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары һәм уку йортларында көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш һәр балигъ булган кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертү чараларын кертергә, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;
2) урам яктырту җайланмасы (лампаларны сатып алу һәм алыштыру);
3) торак пункт территориясен төзекләндерү (паркны саклау).

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Салдакай авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Якушкино авыл җирлеге башлыгы Х.Х. Хәмидуллин